Мордовия Главасы Артём Здунов vзенен Телеграм-каналында мошенникларга ышанмаска чакыра.
Артём Алексеевич болай дип язган: «Дуслар, телефоннан сойләшкәндә уяу булуыгызны vтенәм. Телефон аша мошенниклык очраклары ешайды. Жинаятьчеләр янәсе республика житәкчелеге, министрлыклар һәм ведомстволар, хокук саклау һәм контроль органнары вәкилләре исеменнән шалтырата. Хезмәткәрләр белән сойләшергә, банк хезмәткәрләре аша «проблеманы хәл итәргә», видеоэлемтәгә чыгарга, акчаларны кvчерергә, шул исәптән СВО ихтыяжларына, сугыш хәрәкәтләреннән зыян кvрvчеләргә ярдәм итәргә сорыйлар.      Жуликларнын корбаны безнен дуслар, туганнарыбыз, кvршеләребез һәм танышларыбыз була. Бvген, мәсәлән, бер авыл жирлеге башлыгыннан акча урлауны булдырмый калдык. Тагын бер тапкыр игътибарлы һәм сак булырга чакырам. Акчагызны Ватаныбызнын мошенникларына һәм дошманнарына бирмәгез! Әгәр провокацион характердагы мәгълvмат булган шалтырату кергән икән - уйланылмаган гамәлләр кылмагыз, акчаларны янәсе «куркынычсыз счетларга» кvчерvдән тыелыгыз, шалтыратучылар белән язышуга яки контактка кермәгез. Шалтыратучы турындагы мәгълvматны РМ эчке эшләр министрлыгынын - 8-8342-47771 һәм Мордовия буенча Россия Федераль иминлек хезмәтенен - 8-8342-282828 телефоннары аша тикшерегез».